# МӨХӘММӘТШИН ГАРИФҖАН. КАРИЛЕ – КАРА ИЛЕ[1]

Авылда туган һәркем өчен Туган җир төшенчәсе Туган авыл исеме белән тәңгәл килә. 1917 ел Октябрь инкыйлабы һәм ул алып килгән кискен үзгәрешләр милли гореф-гадәтләрне искелек калдыгы дип игълан итте, төп максат итеп коммунизм төзүчеләр тәрбияләүне куйды, кешеләрнең менталитетын тамырдан алыштырды, бер сүз белән әйткәндә, тарихи дәвамлылыкны өзде. Авыл тарихы белән шөгыльләнүчеләр – гаилә, нәсел, авыл дәрәҗәсендә, ягъни иң нечкә, катлаулы өлкәдә шушы тарихи дәвамлылыкны ялгаучылар, тарихи хәтерне торгызучылар, милли горурлыкка нигезләнгән үзаң формалаштыручылар алар. Алар кулында гаять тәэсирле көч бар. Ул – авылдашларының үрнәк булырлык күркәм гамәлләре, уй-хыяллары. Чөнки туганыңның, авылдашыңның шәхси үрнәге – тормыш мисалы, үткән буыннар турында хәтер яңарту – ниндидер купшы сүзләргә караганда ныграк тәэсир итә, еш кына алда торган катлаулы мәсьәләләрне чишү юлларын билгели, күрсәтә.

Күренекле шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, төбәк тарихын өйрәнүче Гарифҗан ага Мөхәммәтшин Татарстанның Балтач районы тарихы һәм анда яшәүчеләр турында ике томлык энциклопедия бастырып олы фәнни батырлык эшләгән иде. Ә туган авылы Арборга багышланган саллы хезмәте авторның Кариле авылы турында язылачак китабына әзерлек булган икән.

«Кариле – Кара иле» китабы авторның «Кереш сүз»е белән ачыла. Текст өч бүлектән тора, алар хронологик яктан 1917 елга кадәрге заманны, Совет чорын, һәм 1992 елдан бүгенгегәчә вакытны үз эченә ала. Төп текстны берничә күләмле кушымта тулыландыра.

Бу хезмәт күп ягы белән гаҗәпкә калдыра, шаккатыра. Беренчедән, күләме белән. Бер авыл турында 100 басма табаклык китап нәшер итү бик сирәк күренеш. Икенчедән, мавыктыргыч әдәби тел белән язылуын махсус әйтми мөмкин түгел. Авторның авыл тормышын белеп, карилеләргә олы хөрмәт белән багып, яратып язылган китапны укый башлагач, аерылып булмый. Тарихны шулай мавыктыргыч итеп сурәтләү авторның язучылык талантын ачык күрсәтә. Өченчедән, туган авыллары тарихын булдыру карилеләрнең берсен дә битараф калдырмаган. Һәрберсе истәлекләре, гаилә фотоальбомындагы ядкарьләр белән, рухи яки матди яктан ярдәм итеп, авыл җәмгыятенең уртак проектына үз өлешен кертергә тырышкан, шул рәвешле китапның гаҗәп кызыклы эчтәлекле һәм сурәтләргә бай булуын тәэмин иткән. Бу хакта басманың титул битендә урнаштырылган «Китап Гөлсем Миңнебаеваның

[1] Мөхәммәтшин Гарифҗан. Кариле – Кара иле. Казан: ПИК «Идел-Пресс», 2017. 856 б.

тырышлыгы белән авылыбыз эшмәкәрләре һәм авыл халкыннан җыелган акча хисабына чыгарылды» дигән җөмлә искәртә.

Хезмәтнең уңышы – авторның авыл тарихына бәйле булган барлык төр чыганакларны да оста куллануында. Үзәк һәм төбәк архивларында саклаучы яки басылган халык санын алу һәм метрикә кенәгәләре, кабер ташлары, шулай ук земство, архивлардагы хакимият органнары кәгазьләреннән бөртекләп җыелган мәгълүматлар, тарихи хезмәтләрдә чагылыш тапкан материаллар авыл җәмгыятенең берничә гасырлык социаль тормышын күзалларга мөмкинлек бирә.

Китапның үзәгендә – мәшһүр шәхесләр, иҗтимагый һәм дәүләт оешмалары. 1917 елгы инкыйлабка кадәрге чорда авылга нигез салыну тарихы, игенче җәмгыяте һәм лашманнарның социаль хәле, мәхәллә, мәчет-мәдрәсә, имам-мөгәллимнәр, сәүдәгәрләр сурәтләнә, авыл тарихында табигать һәм тормыш афәтләре, Пугачев баш күтәрүендә катнашу кебек вакыйгалар яктыртылган. Китаптан күренгәнчә, Кариленең «чәчәк аткан» вакыты XVIII гасырның урталары – XIX йөз урталарына туры килә. Бу еллар – халыкның лашман бурычын үтәгән (1752–1859 еллар), ярминкәләр илнең төп сәүдә үзәкләре булган һәм әле Россия сәнәгатенә техник үзгәртеп-кору кермәгән заман. Карилеләр шушы вакыт арасында йомышлы татарлар кебек (бигрәк тә XVIII гасырның урталарында) төрле төбәкләргә иркле бару һәм сәүдә итү мөмкинлегеннән оста файдаланганнар. Сәүдә эшенә көзге-кышкы айларда ерак урманнарда агач кискәндә оешкан лашман артельләрендә үзара ярдәмләшү, бару-кайту юлында һәм эш барышында рус телен өйрәнеп шомарган туганнар һәм авылдашларның кооперация-хезмәттәшлеге нык ярдәм иткән, дип уйлыйбыз.

Кариледә бердәм һәм кыю халык яшәгәнен 1742 елда мәчетләрне массакүләм япканда гыйбадәтханәне саклап калу, Пугачев җитәкчелегенә баш күтәрү елларында хакимиятне үз кулларына алып яшәүләре, баш күтәрүчеләр ягында сугыш хәрәкәтләрендә катнашулар раслап тора.

Алар беренче капиталны Оренбург якларындагы меновой дворларда яки Урта Азиягә баручы кәрваннарда йөкче-хезмәтче, казакъ даларында йөкче яки ваклап сатучы буларак туплап, яңа яшәү урыннарына туганын чакырып, алыш-бирешне киңәйтеп баеп киткәннәр, дип фаразлыйбыз. Рус телен үзләштерү аларга Казанда да сәүдәгәр дәрәҗәсенә ирешү мөкинлеген биргән. Нәкъ менә шул елларда авылдан чыгып Юнысовлар, Усмановлар Казанда күренекле бай нәселләргә әверелгәннәр. Карилеләр шулай ук Оренбург, Троицк, Семипалатинск, Петропавловск шәһәрләренә туганнарын алдырып сәүдә эшләрен җайга салганнар, болар хакында китапны киләчәктә эзләнүләрне дәвам итәргә өндәүче өзек-өзек мәгълүмат урын алган.

Авылда байлар элегрәк тә булган дип фаразларга нигез бар. Чөнки данлыклы мәдрәсәләр бай

белән гыйлем иясе бердәмлеге нигезендә генә төзелә. Беренчесе матди базаны һәм мөдәрриснең һәм шәкертләрнең яшәү шартларын, ризыкларын кайгыртса, икенчесе сабак биргән. Кариленең әлегә исемнәре билгесез байлары ярдәме белән Уфа губернасыннан килгән Габдессәлам хәзрәт, XVIII гасырның икенче чирегеннән башлап, 60 ел дәвамында мөдәррислек итеп, авыл мәдрәсәсен төбәкара ислам белеме бирү үзәгенә әверелдерә, берничә буын тирән гыйлемле руханилар әзерләүгә зур өлеш кертә. Китапта язылганча, XIX гасыр башыннан Кариледәге уку йорты башка авыллардагы кебек гадәти башлангыч мәктәп булып кала, моның сәбәпләренең берсе – укытуның сәүдә-табыш эшен алгы планга куйган муллалар буыны кулына күчү. Китапта китерелгән земство статистика мәгълүматлары XIX гасыр азагында – XX йөз башында авыл халкының нигездә игенчелек белән шөгыльләнгәнен раслый, шулай ук кибетләр тотучы берничә шәхес булуы элекке традицияләрнең югалмавына ишарәли.

Совет чорына багышлаган бүлекнең уңышы – хезмәтне хуҗалык кенәгәләрен, район газетасы материалларын, өлкән буын вәкилләреннән махсус яздыртылган истәлекләрне уңышлы файдалану һәм авторның, замандаш буларак, үз тормыш тәҗрибәсенә таянып язуында. Текстларда балалар бакчасы, мәктәп, клуб, китапханә, медицина пункты кебек сәламәтлек саклау, уку-укыту һәм мәдәни институтлар, социаль объектлар, почта бүлекчәсе, үзидарә органы булган авыл советы эшчәнлеге, колхоз һәм сәнәгать оешмалары эшчәнлеге, үзешчән сәнгатьтә катнашу, спорт, ял итү һәм күңел ачу чаралары аша совет идеологиясе урнашу, төрле буын вәкилләренең тормыш-көнкүреше яктыртыла, җирле интеллигенциянең халыкның мәдәни тормышында, яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә тоткан урыны билгеләнә.

Ил буенча авылда яшәүчеләр саны кимегән бер вакытта, Кариле үсеш кичерә. XX гасырның соңгы өч дистә елында Кариле төбәкара сәнәгать үзәгенә кагылышлы торак пункты буларак үсә, Тимирязев исемендәге колхоздан тыш чиктәш Нормада ачылган «Сельхозтехника» берләшмәсе бирегә күрше авыллардан күченеп төпләнүчеләрне арттыра. Берничә чакрымдагы район үзәге оешмаларына барып эшләүчеләрне исәпләсәң, авыл кешеләренең социаль йөзе эшчеләр поселыгында көн итүчеләргә туры килә. Республикада андый авыллар күп түгел. Иҗтимагый һөнәр бүленеше ягыннан эшчеләр поселыгы, ә рәсми кәгазьләрдә авыл буларак теркәлгән Кариле мисалында торак пункты тарихын язу тәҗрибәсе махсус өйрәнүгә лаек.

Китапның өченче бүлеге бераз үзгә структурага нигезләнгән. Очерклар авыл тормышының төрле якларын ачу концепциясе кысаларында язылган. Биредә Кариленең ил мәнфәгате белән яшәп, авыл кешеләренең чирәм җирләрне үзләштерүе, Бөтенсоюз төзелешләрендә катнашулары,

совет армиясендә хезмәт итүләре, күрше өлкә һәм союздаш республикаларда алар ирешкән хезмәт җиңүләре сурәтләнә. Төп идеяне ачарга күп балалы гаиләләр, авылга радио, электр, телефон челтәрләрен сузу, су колонкалары кую, газ кертү, совет кешесенең тормыш дәрәҗәсенең төп маркерлары булган телевизор, мотоцикл, җиңел машина алу, социаль объектлар һәм мәчет төзү, дини йолаларның кайтуы, сабантуйлар турында сюжетлар, җирле топонимия турында язмалар нык ярдәм итә.

Китапта урнаштырылган төрле чорларга караган фотолар хакында махсус искәртү мөһим. Аларның саны бихисап. Фотосурәтләр төрле буын карилеләрнең йөз-кыяфәтләрен, аларның үткән һәм бүгенгесе тормышын чагылдыручы кыйммәтле чыганак булудан тыш, бер авыл мисалында милләтебезнең тарихи дәвамлылыгын гәүдәләндерә.

Автор карилеләрне бик калку итеп күрсәтү мөмкинлеген тапкан. Аларның кайберләре төп текстта Россиядә бертуктаусыз барган һәм бүген дә дәвам итүче реформалар фонында, авылның социаль тормышын сурәтләгәндә күреп-күренеп китә. Ә китапның кушымтасында урнаштырылган биографик белешмәләр, очерклар бу булдыклы шәхесләрне тулырак итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Киңкырлы эшчәнлекләрен исәпкә алып, берничә буын авыл кешеләре хакында материаллар «Кариле йолдызлыгы», «Кариле шәҗәрәләре», «Кариле авылыннан Бөек Ватан сугышына китеп, җиңүне яулап кайтучылар һәм шәһит булганнар», «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында батыр хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнгән авылдашлар исемлеге», «2016 елның 28 октябрендә Кариле авылында яшәүчеләрнең исемлеге», «Кариле бизәкләре» (фотолар), «Карилеләр иҗаты» исемле бүлекләрдә бирелгән.

Кушымтада урнаштырылган 1678 елгы җан исәбе алу кенәгәсе һәм 1722, 1744, 1762, 1795, 1812, 1816, 1833, 1850 елгы ревизия материаллары, табылган кадәр метрикалардан һәм ЗАГС язуларыннан күчермәләр (1834, 1835, 1842, 1843, 1845, 1846, 1848, 1850, 1855–1857, 1860, 1864–1889, 1891–1929, 1931–1939, 1942–1952 еллар) урнаштыру кыйммәтле массакүләм тарихи чыганакларны иҗтимагый әйләнешкә кертергә мөмкинлек бирә. Китапта тупланган мәгълүматлар ярдәмендә яңа буын вәкилләре мөстәкыйль рәвештә нәсел шәҗәрәләрен төзи, бабаларының килен алып, кыз биреп күрше авыллар кешеләре белән туганлашу тарихын һәм никахлашучыларның яшьләрен, гаилә әгъзалары санын һәм уртача гомер озынлыгын, кайсы айларда балаларның күбрәк туу вакытын, чит төбәкләрдән килеп төпләнүчеләрне һәм башка кайбер демографик тарих битләрен яза алалар.

Инде килеп китаптагы хаталарга тукталыйк. Алар юк түгел, күбесе беренче бүлеккә карый һәм XVI–XVII гасыр тарихының начар өйрәнелгән булуы, авторның тарихи чыгакларны төгәл анализламавы белән аңлатыла.

Без җитешсезлекләрне берничә төркемгә бүлдек.

*Терминнар.* Билгеле булганча, XVI–XVII гасырларда рус хакимияте тарафыннан уздырылган йорт хисабын алу йорт башыннан салым алу өчен үткәрелгән һәм «писцовый кенәгәләргә» теркәлгән. Петр I дән башлап 1858 елга кадәр игенчеләр һәм мещан җәмгыятьләренә салым бүлү максатында уздырылган халык исәбен алу кәгазьләре «ревизские сказки» дип аталган. Россиядә ревизияләр 10 тапкыр үткәрелә: 1719, 1744 (текстта 1740), 1762, 1782 (текстта 1780), 1795, 1811 (китапта 1812), 1816 (текстта аерым төбәкләрдә генә булган диелә), 1834, 1850, 1858 елларда. XVII гасырда йорт исәбен һәм җан исәбен алу «ревизия» дип аталмаган, 1897 елгы Европа статистика тәртибе нигезендә уздырылган Бөтенроссия халык санын алуны (соңгысы китапта 1895 елгы дип язылган) да өстәү дөреслеккә туры килми (13 б.). Хезмәттә Адмиралтейство хезмәтендәгеләрне XIX гасырда «лашман» дип атый башлаганнар диелә (18 б.). Әмма лашман термины 1762 елгы документларда ук очрый (А. Свечин комиссиясе документлары). «Подушная подать» XVII гасырда түләнмәгән (30 б.). Ул – Петр I тарафыннан беренче ревизия мәгълүматларына нигезләнеп исәпкә алынган һәрбер ир-ат крестьянга һәм мещанга керткән салым.

*Авылны нигезләү вакыты.* 40 нчы биттә Кариле авылы XVII гасыр башында нигезләнгән диелсә, 41 нче биттә 1570–80 елларда диелгән. Кариле авылының нигезләнү вакыты 1570–1580 елларга туры килә дип (9 б.) катгый итеп әйтү сораулар тудыра. Бәлки, ул элегрәк барлыкка килгәндер? Чөнки 1678 елгы халык санын алу буенча яшәүчеләрнең саны кариленекеннән күпкә кимрәк Казан ханлыгы чоры авыллары билгеле. Шул сәбәпле, халык саны буенча, 1678 елда яшәүчеләрнең авылга нигез салучыларның икенче-өченче буыны булуы аңлашыла диюгә нык-лы нигез юк.

*Авылның исеменең килеп чыгышы.* Китапта авылның Кари исеменнән килеп чыкмаганлыгына 1678 елгы документта Кари исеменең очрамавы нигез итеп китерелә (15 б.). Ул заманда киң таралган кеше исеме булган һәм авылга нигез салырга мөмкин булган Каринең элегрәк яшәгән булуы да бик мөмкин.

*Авылга нигез салучылар.* 1678 елда фәкать ясаклы авылларда яшәүчеләр генә исәпкә алынган. Димәк, бу вакытта Кариледә йомышлы татарлар түгел, ә ясаклы татарлар көн күргән. Ә нократ-кариле татарлары статуслары буенча йомышлы татарлар иде. Илдус Габдуллин хезмәтендә телгә алынган документта, нократ-кариле татарларының берничә авылда, шул исәптән Кариледә дә булулары турындагы хәбәр XVIII гасырның беренче яртысына карый. Ә XVIII йөз ревизия кенәгәләрендә Кариледә барлык кеше дә ясаклы крестьяннар, ягъни дәүләт крестьяннары диелгән. Димәк, нократ-кариле татарлары авылда бер мәлне генә яшәп алганнар. Электән ясаклы татарлар сословиясенә караган

Кариле авылы халкының яки аерым бер нәселенең Казан ханлыгы чорындагы аристократия нәселенә ялгана алуы бик шикле.

12 биттә Кара бәк шәҗәрәсенә караган «Кара би – Мөхәммәд би – Ильяс – Мирсәйет – Дүнәш – Җанчура – Җансәйет» нәселе линиясен Кариле авылы ревизия кенәгәләрендә таптык, дип белдерү документларга нигезләнмәгән (әйтик, китапта китерелгән 1678 елгы халык исәбен алу һәм 1722, 1762 ел ревизия материалларыннан алынган мәгълүматлар – «Яким – Янгилде – Үтәк – Мәмәт (1672–?) – Йосыф (1711–?) – Габделваһаб (1733–?)» линиясен төзи. Буыннар арасын 25–30 ел дип исәпләгәндә, Яким якынча 1580 елларда яки иртәрәк туган булырга мөмкин. Дүнәшнең 1548 елгы икәнлеген исәпкә алсак[1], аннан «Яким – Янгилде – Үтәк линиясе» китәргә тиеш булыр иде. Тик китапта 12 биттә күрсәтелгән «Дүнәш – Җанчура – Җансәйет» линиясе белән «Яким – Янгилде – Үтәк» линиясе арасында бернинди дә бәйләнеш күренми. Соңгы линия күпмедер үзгәрешләр белән 431 биттә Карабәк шәҗәрәсе дип исемләнгән шәҗәрәдә күрсәтелгән («Яким (Янка) – Янгилде – Кутнек (Кибәк) – Мәмәт – Йосыф – Габделваһаб (1733–?)» линиясе). Монда Үтәкне ни рәвешле Кутнек (Кибәк)кә әйләндерү аңлашылмый.

Без, тел тарихы белгечләре фикерләренә таянып, Карилеләрнең ерак бабалары ногайлар булган дигән фикердә калабыз.

Әлбәттә, аталган кимчелекләр хезмәтнең фәнни дәрәҗәсен киметми, ә авыл оешу вакытын тагын да җентекләп, яңа чыганаклар табып өйрәнергә кирәклеген кенә искәртә.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,***
*тарих фәннәре докторы,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*яңа тарих бүлеге мөдире*

***Фәйзрахманов Илшат Җәүдәт улы,***
*тарих фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

[1] Исхаков Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени (Этнологический взгляд на историю волго-уральских татар XV–XVII вв.). Казань, 1998. С. 34.